РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ЮЛБАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

422077, Республика Татарстан,
с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57
тел. (84362) 43-7-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЮЛБАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422077, Татарстан Республикасы,
Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт
тел. (84362) 43-7-22

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
16.10.2023

КАРАР
№ 5

Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Башлыгының 27.01.2016 елгы №2 карары белән расланган Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советы вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү Тәртибенә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатында,

КАРАР БИРӘМ:

1. Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Башлыгының «Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советы вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү Тәртибен раслау турында» 2016 елның 27 гыйнварында 2 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советы вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү Тәртибенә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 2.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Гражданның мөрәҗәгате (алга таба - мөрәҗәгать) - җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка язма рәвештә яки электрон документ рәвешендә, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып (алга таба - Бердәм портал), тәкъдим, гариза яки шикаять, шулай ук гражданның җирле үзидарә органына телдән мөрәҗәгать итүе.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ulbat адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Юлбат авыл җирлеге Башлыгы Т.Р. Шәмсиев